**Азнакай муниципаль районы**
**Татар Шуганы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татар Шуганы авылы № 93 «02» октябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советының 2016 елның 01 июнендэге 34 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2016 елнын 26 октябрендэге 41 номерлы, 2017 елның 19 сентябрендэге 67 номерлы, 2018 елнын 01 февралендэге 85 номерлы, 2019 елның 30 декабрендэге 161 номерлы, 2020 елның 09 апрелендэге 170 номерлы, 2021 елның 23 сентябрендэге 37 номерлы, 2023 елның 06 апрелендэге 79 номерлы, карарлар редакциясендә)

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 345-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Татар Шуганы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советының 2016 елның 01 июнендэге 34 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә ( 2016 елнын 26 октябрендэге 41 номерлы, 2017 елның 19 сентябрендэге 67 номерлы, 2018 елның 01 февралендэге 85 номерлы , 2019 елның 30 декабрендэге 161 номерлы , 2020 елның 09 апрелендэге 170 номерлы , 2021 елның 23 сентябрендэге 37 номерлы , 2023 елның 06 апрелендэге 79 номерлы , карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 бүлекнен 1 пунктында:

а) алтынчы абзацта «, газ бүлү челтәрләре, газ куллану челтәрләре һәм мондый челтәрләр объектлары» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац белән тулыландырырга:

«- газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына карата «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру

турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 30.5 статьясында каралган башка шартлар;»;

в) сигезенче, тугызынчы абзацларны тугызынчы, унынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карар 2023 елның 23 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.Ш.Хаертдинов